СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.12.2024 г. Агрыз № 43-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының "Муниципаль учреждениеләрне муниципаль мөлкәтне карап тотуга бәйле коммуналь һәм эксплуатация хезмәтләрен каплау бурычыннан азат итү турында" 14.12.2023 елның 33-7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Муниципаль учреждениеләрне муниципаль мөлкәтне карап тотуга бәйле коммуналь һәм эксплуатация хезмәтләрен каплау бурычыннан азат итү турында» 14.12.2023 елның 33-7 номерлы карарына (алга таба — Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә укырга:

«1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы аша «ссуда бирүче» белән һәм муниципаль учреждениеләр аша «баланс тотучы» белән төзелгән муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәләре (алга таба – шартнамә) буенча «ссуда алучылар» булган муниципаль учреждениеләрне муниципаль мөлкәтне баланс тотучыларга коммуналь һәм эксплуатация хезмәтләрен,муниципаль мөлкәтне карап тотуга бәйле түләү бурычларыннан азат итәргә.

Әлеге карарның шушы пунктында күрсәтелгән бурычларны муниципаль мөлкәтнең баланс тотучысына йөкләргә.

Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә әлеге карар чыгарылган көннән алып утыз календарь көннән артмаган срокта муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалануның гамәлдәге шартнамәләренә үзгәрешләр кертү турында тиешле гариза белән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасына мөрәҗәгать итәргә йөкләмә бирергә.».

2.Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга,

Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигать ресурслары һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов